# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ОЛЫ ҖӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## РЕШЕНИЕ
## КАРАР

**01 сентябрь 2023ел** **№124**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Җәке авыл җирлеге Советы 2021 елның 21 июлендәге 36 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (Олы Җәке авыл җирлеге Советының 2022 елның 7 сентябрендәге 73 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Терлекләр белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Олы Җәке авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Олы Җәке авыл җирлеге Советының 2021 елның 21 июлендәге 36 номерлы карары белән расланган (Олы Җәке авыл җирлеге Советының 2022 елның 07 сентябрендәге 73 номерлы карары белән үзгәрешләр кертелгән) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Җәке авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (алга таба - Кагыйдә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Кагыйдәләрне түбәндәге эчтәлекле 1 нче кушымта белән тулыландырырга:

Кушымта №1 Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Җәке авыл жирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча №124 01.09.2023

**Исемлек**

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Җәке авыл җирлеге территориясендә терлекләрне хуҗалардан башка кайтару тыела торган урыннар**

1. Балалар уен һәм спорт мәйданчыклары, спортның актив төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.

2. Иҗтимагый территорияләр (парклар, скверлар территорияләре, массакүләм ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр полосалары).

3. Мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.

4. Мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.

5. Җәмәгать туклануы оешмаларына, сәүдә объектларына якын территорияләр, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннары.

6. Зират.».

2. Хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затларның түбәндәге исемлеген билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Җәке авыл жирлеге башлыгы;

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Яке авылы, Мәктәп урамы, 1 йорт (администрация бинасы), Олы Яке авылы, Мәктәп урамы, 1а йорт (Олы Җәке авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чykканнан соң үз көченә керә.

Олы Җәке Авыл жирлеге Башлыгы: Ф.А.Фәйзуллина